КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2023 елларга Татарстан Республикасында халыкның финанс белемлелеге дәрәҗәсен арттыру һәм финанс белемен үстерү» төбәк программасын раслау турында» 2020 ел, 08 декабрь, 1100 нче карары белән расланган «2020 - 2023 елларга Татарстан Республикасында халыкның финанс белемлелеге дәрәҗәсен арттыру һәм финанс белемен үстерү» төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2023 елларга Татарстан Республикасында халыкның финанс белемлелеге дәрәҗәсен арттыру һәм финанс белемен үстерү» төбәк программасын раслау турында» 2020 ел, 8 декабрь, 1100 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 март, 342 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2020 - 2023 елларга Татарстан Республикасында халыкның финанс белемлелеге дәрәҗәсен арттыру һәм финанс белемен үстерү» төбәк программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең утыз алтынчы абзацында «2016 елның 26 августындагы 596 номерлы» сүзләреннән соң «булды» сүзен өстәргә, «республика башкарма хакимиятенең профильле органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимиятенең тармак республика органнары» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең унбишенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин